КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 7 апрель г.Казань № 214

Һәрвакыт авыл җирлегендә яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләүне бирү буенча чыгымнарны финанслау тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Һәрвакыт авыл җирлегендә яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү турында» 2018 ел, 9 февраль, 67 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Механизм Карарга теркәлгән Һәрвакыт авыл җирлегендә яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләүне бирү буенча чыгымнарны финанслау тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда Һәрвакыт авыл җирлегендә яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләүгә акча каращ.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

3. Бу карарның гамәле 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарала дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 7 апрель, 214 нче карары белән расланды

Һәрвакыт авыл җирлегендә яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләүне бирү буенча чыгымнарны финанслау
ТӘРТИБЕ

1. Бу Тәртип Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Һәрвакыт авыл җирлегендә яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү турында» 2018 ел, 9 февраль, 67 нче карары белән билгеләнгән Һәрвакыт авыл җирлегендә яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләүне (алга таба – бер тапкыр бирелә торган түләү) бирү чыгымнарын финанслау механизмын билгели.

2. Бер тапкыр бирелә торган түләүне бирү буенча чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү әлеге максатларга тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары кысаларында гамәлгә ашырыла.

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) ай саен, агымдагы айның сигезенә кадәр Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына бер тапкыр бирелә торган түләү бирү чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә заявка (алга таба – заявка) җибәрә.

4. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы ай саен Министрлык заявкасы буенча аңа финанслауның чик күләмнәрен җиткерә.

5. Министрлык ай саен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан финанслауның чик күләмнәре җиткерелгән көннән соң биш эш көне эчендә аларны «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесенә (алга таба – Үзәк) оештыру заявкасы формасында электрон рәвештә, алга таба гражданнарның банка яки бүтән кредит оешмаларында ачылган шәхси счетларына күчерү өчен «АЦК-Финансы»га күчерүне гамәлгә ашыра.

6. Үзәк ай саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 10ысыннан соңга калмый, Татарстан Республикасы бюджетыннан тотылган чыгымнар турында Министрлыкка хисап тапшыра.

7. Министрлык ай саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 15еннән соңга калмый, Татарстан Республикасы бюджетыннан тотылган чыгымнар турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына хисап тапшыра.

8. Әлеге Тәртипнең 6 һәм 7 пунктларында күрсәтелгән хисаплар Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән форма буенча тапшырыла.

9. Хисапта тапшырыла торган мәгълүматларның дөрес булмавы һәм акчаны максатка ярашлы кулланмаган өчен Министрлык һәм Үзәк Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә җавап тота.

10. Әлеге Тәртип нигезендә бирелгән акчаны максатчан куллануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.